| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.10.2020 г.Казань № 669

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 14 октяберендә 6881 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 ел № 484, 16.08.2019 ел № 624, 14.11.2019 ел № 1023, 18.06.2020 ел

№ 436, 27.07.2020 ел № 536 боерыклары керткән үзгәрешләр) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләрне расларга.

Министр в.б. Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының
2020 елның 24 сентябрендәге
669 номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
2018 елның 31 августындагы 825 номерлы «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә
мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең
хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

2.14 пунктның 2 бүлегендәге «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Инвалидларга законнар чыгару һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә объектлардан файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән хезмәт күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектларга һәм хезмәт күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән хезмәтләрне алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-ноктылы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, хезмәт күрсәтүләр башкарыла торган объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга хезмәтләрдән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып хезмәт күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче орган һәм оешма хезмәткәрләренең инвалидларга башка затлар белән тигез хезмәтләр алуга комачаулаган киртәләрне үтәргә ярдәм итүе;

г) хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-ноктылы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

Регламентка 11[1] нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданны өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны
озак вакыт тәрбияләү системасын төзү буенча пилот проектында 2020-2022
елларда катнашучы социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан өлкән яшьтәге
гражданнарга һәм инвалидларга көндезге төркемнәрдә ярымстанционар
рәвештә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле,
гариза бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы

муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) территориаль органына яшәү урыны буенча тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| № п/п | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ бирә торган оешма | Документның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен раслаучы документлар «*» | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, опека һәм попечительлек органы | законнарда билгеләнгәнчә |
| 2. | Инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасы «**» | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләүнең шәхси программасында күрсәтелгәнчә |
| 3. | Өлкән яшьтәге кешенең хәтер белән проблемалары (деменция, картлык астениясе) (МКБ-10 буенча диагноз: F00-F03, R54) яки когнитив бозылулар (МКБ-10 буенча диагноз: F70, F71) булуын раслый торган белешмә «***» | медицина оешмалары | законнарда билгеләнгәнчә |
| 4. | Җиңел яки уртача зиһен бозылуын (МКБ-10 буенча диагноз: F70, F71) яки югары функцияле аутизм (Аспергер синдромы) (МКБ-10 буенча диагноз: F84.5) булуын раслый торган белешмә «****» | медицина оешмалары, Татарстан Республикасының психоневрология интернатлары (тиешле психоневрологик интернатның социаль хезмәт күрсәтүләрен алучыларга) | законнарда билгеләнгәнчә |

«*» - гаризаны гариза бирүченең законлы вәкиле биргән очракта, билгеләнгән тәртиптә хокукка сәләтсез яки хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затларга хезмәт күрсәтүгә китерелгәндә тапшырыла;

«**» - инвалидларның федераль реестрында тиешле белешмәләр булмаган очракта инвалидларга тапшырыла;

«***» - өлкән яшьтәге гражданнарга тапшырыла;

«****» -18 яшьтән башлап һәм өлкәнрәк инвалидларга тапшырыла.».